Агымдагы елнын сентябрендә Мордовия халкы мошенникларга 51 миллион сумнан артык акча кvчергән.  Бу айда жинаятьләр кылунын ин кин таралган ысуллары булып элемтә хезмәтләре шартнамәләренен (договор) гамәлдә булуын озайту, акчаларны резерв счетына кvчерv һәм билгесез кешеләр тарафыннан тобәк халкына кредитлар рәсмиләштерv тора. Шул рәвешле 29 миллионнан артык кешедән 70 кеше мәхрvм калган. Унике миллион сум тирәсе зыян кvрvче тvләvсез белдерvләр сайтында, социаль челтәрләрдә, популяр маркетплейслар платформасында товарлар сату һәм сатып алу вакытында югалткан. Тагын 19 кеше мошенникларга эшкә урнашу һәм акчаларны инвестицияләv сылтавы белән 7 миллионга якын акча кvчергән.
Мордовия Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы гражданнарга: әгәр сезгә кешеләр шалтыратып, банк яки полиция хезмәткәрләре дип таныштырсалар, финанс оешмаларынын һәм хокук саклау органнарынын рәсми номерлары буенча шалтыратыгыз, дип искәртә. Алдан тvләv сыйфатында товар очен акча кvчермәгез, шулай ук банк карталарынын тулы реквизитларын, PIN-кодны, CVC/CVV-кодларны һәм операцияләрне раслау очен бер тапкыр кулланыла торган парольләрне беркемгә дә хәбәр итмәгез. Сезгә акча кvчерv очен банк картасы номеры гына житә.
Пенсионер хатын-кыз эш тәкъ-диме белән мошенникларнын корбаны булган. Россия Эчке эшләр министрлыгынын Саранск буенча 1 нче ОПка 1965 елгы жирле хатын-кыз vзенә карата жинаять кылу турында гариза белән морәжәгать иткән. Полиция хезмәткәрләре ачыклаганча, популяр мессенджер аша ана интернетта акча эшләv турында тәкъдим кергән. Маркетплейс хезмәткәрләре дип таныштырган билгесез кешеләр хатын-кызга товарларны алга жибәрv буенча яхшы тvләvле эш тәкъдим иткәннәр. Агымдагы елнын 28 сентябреннән 2 октябренә кадәр пенсионер «эш бирvче»нен катлаулы булмаган кvрсәтмәләрен vтәгән. Аннары мошенниклардан товарларнын берсе очен алдан тvләv vтенече килә. Ана бу «анын хезмәтенә ихтыяж һәм тvләv дәрәжәсен арттыру»очен кирәк, дип анлаттылар. Хатын-кыз, якыннары белән кинәшмичә, жинаятьчеләр кvрсәткән счетка 200 мен сумнан артык акча кvчергән. Шуннан сон анардан «бизнесны алга таба vстерv»кирәклеге сылтавы белән тагын шундый ук сумманы алдарга тырышып карадылар. Бу этапта гына пенсионер, туганнарына «эш» турында сойләп, аферистларнын корбаны булуын анлаган һәм полициягә морәжәгать иткән.
Шуны истә тотарга кирәк: әгәр эш яки акча алу очен vз акчанны каядыр кvчерергә кирәк икән-бу 100% мошенниклык. Ят кешеләр басымы астында бернинди финанс операцияләре ясамаска һәм vгетләvләргә бирешмәскә. Зур суммаларны кvчерv алдыннан туганнары яки банк хезмәткәрләре белән кинәшләшергә кирәк.